| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГОРОДА БУИНСКА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУА<br>ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 28 гыйнвары Буа шәһәре № 6

Мунча хуҗалыгы оешмаларына субсидияләр
бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 06 октябрендәге 67 номерлы «Мунча хуҗалыгы оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган мунча хуҗалыгы оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.3. пункты:

Түбәндәге редакциядәге абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирү ярдәм итү чарасын алуның мәҗбүри шарты булып тора.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемә йөклим.

Буа шәһәре Башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Я. Галәветдинов